

Үткән атнада жирле vзидарә хезмәткәрләре vзләренен һонәри бәйрәмнәрен билгеләп vттеләр.

Доньяда бар нәрсә дә vзгәрә, ә авыл хезмәте элеккечә барысына да кирәк. Сезнен жиргә хужаларча караш, хезмәтне ярату белән авыл хужалыгы тармагын – тормыш нигезен, авылнын яшәv рәвешен, кvптәнге традицияләрен саклыйсыз һәм vстерәсез. Әлеге бәйрәм конендә авылда яшәгән һәм жирдә эшләгән һәркемгә чын кvнелдән рәхмәт әйтәбез. Хезмәтегезгә бирелгәнлек һәм тугрылык очен рәхмәт. Шундый хезмәт кәрләр арасында лаеклы Фәрит Тахир улы Эртугановны атыйбыз.

Торбеево районы Сыркыды - Сургодь авыл жирлеге администрациясен 2013 елнын мартыннан Фәрит Тахир улы Эртуганов житәкли. Анын житәкчелегендә авыл жирлеге Торбеево районынын авыл территорияләре арасында vткәрелгән хезмәт ярышында берничә тапкыр жинvче иде. Ә сонгы елларда биредә vзгәрешләр дә шактый кvп булды. 2018 елда Сургодь авыл жирлеге Лопатино авылы белән берләште һәм Фәрит Тахир улынын мәшәкатьләре артты. Бvген биредә топ мәктәп, ике ФАП, ике КДЦ, ике авыл китапханәсе, почта, оч кибет эшли. 2019 елда Лопатино авылы Үзәк урамы буенча яна сууткәргеч магистрале салынган.

Фәрит Тахир улы Эртуганов хезмәт союченлеге, vз-vзенә һәм хезмәттәшләренә таләпчәнлеге белән аерылып тора. Сыркыды авыл жирлеге коллективында да зур абруй казана. Хезмәт эшчәнлеге очен Мордовия Главасы һәм Мордовия Госсобраниесе Рәхмәт хатлары белән бvләкләнде, Торбеево муниципаль районы хакимиятенен Рәхмәт хатлары һәм Мактау грамоталары белән кvп тапкырлар бvләкләнгән хезмәткәр ул.

Якташлары хакына хезмәт куйган Тахир улы Фәритнен жинел булмаган эше яна

казанышлар һәм рәхмәтле як ташларыгызнын хормәте белән зурлансын. Киләчәктә дә хезмәт унышла рыгыздан макталыгыз.

*Наилэ НАСЫРОВА*